ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирина Батыршина, д.33,
с.Каракашлы, 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Сирин Батыршин урамы, 33йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-34, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 23** **11 декабрь 2025 ел**

Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә
Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрү чорында
янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү турында

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәм чараларында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 25 декабреннән 2026 елның 12 гыйнварына кадәр Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә янгынга каршы махсус режим кертергә;

2. Учреждениеләрдә янгын куркынычсызлыгы өчен җаваплы затлар итеп түбәндәге җитәкчеләрне билгеләргә:
– Исхакова Эльвира Фатыйх кызын-Кәрәкәшле мәдәният йорты директоры;
- Зарипова Альбина Сәлахетдин кызын-Урал клуб мөдире
- Шәрифуллина Лилия Ринат кызын-Салкын Чишмә клуб мөдире;
- Шәрәфиева Зөлфия Марс кызын-Кәрәкәшле төп гомуми белем бирү мәктәбе директоры;
- Гыйздетдинова Гүзәл Сәгадәтулла кызын - Кәрәкәшле «Ләйсән»балалар бакчасы мөдире.
- Кәрәкәшле авыл җирлеге территориясендә - Мусин М.Н. - Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы.

3. Учреждениеләр җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:
- Яңа ел бәйрәм чараларына әзерлек һәм аларны уздыру чорында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча комплекслы чаралар күрергә;
- Яңа ел бәйрәм чараларын уздыру урыннарын Ютазы муниципаль районында дәүләт янгын күзәтчелеге бүлеге белән килештерергә;
- мәдәни-массакүләм һәм Яңа ел бәйрәм чараларын уздыру урыннарында медицина белән тәэмин итү тәртибен килештерергә;
- урам чыршыларын бизәү сыйфатында сертификацияләнгән электр гирляндаларын кулланырга;
- Яңа ел бәйрәм чараларын үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затларны янгын сүндерү-техник минимум программалары буенча укытуны оештырырга;

4. Предприятиеләргә һәм оешмаларга, КФХ җитәкчеләренә, торак милекчеләренә кышкы вакытта җирлекне, объектларга, торак йортларга һәм янгынга каршы тышкы су белән тәэмин итү чыганакларына юлларны, янгын гидрантларын кар һәм боздан вакытында чистарту эшен оештыруны тәкъдим итәргә;

- халыкка янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүмат бирү эшен оештырырга.
5. Җирлек территориясендә ваклап сату белән шөгыльләнүче шәхси эшмәкәрләргә законнарда билгеләнгән тиешле сертификатлары булмаган пиротехника әйберләрен һәм электр гирляндаларын, шулай ук техник документларында янгын куркынычы күрсәткечләре һәм алар белән эш иткәндә янгын куркынычсызлыгы чаралары күрсәтелмәгән Яңа ел бизәнү әйберләрен, ясалма чыршыларны сатуны булдырмау чараларын күрергә тәкъдим итэргә.
6. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә: Кәрәкәшле авылы, Мирфатыйх Зәкиев ур., 19 йорт., һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының «рәсми Татарстан» бердәм порталын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.
7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Кәрәкәшле авыл җирлеге Башлыгы : М.Н.Мусин